Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Бута авыл Советы

КАРАРЫ

14 май 2019 ел №101

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл җирле үзидарә органнарының закон һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү Нигезләмәсен раслау турында

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл җирле үзидарә органнары эшчәнлеген камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл җирле үзидарә органы тарафыннан кабул ителгән (чыгарылган) муниципаль норматив хокукый актларга һәм законнарга үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү буенча, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл Уставына таянып

Бута авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл җирле үзидарә органнарының законнарга һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турында Нигезләмәне (1 нче кушымта) расларга.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бута авыл җирле үзидарә органнарына:

- үз нормалар иҗат итү эшчәнлегендә әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә таянып эш итәргә;

- күрсәтелгән Нигезләмәнең үтәлеше өчен җаваплы затларны билгеләргә;

- җаваплы затлар тарафыннан билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи күрсәтмәләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарны Бута авылы, Сельская урамы, 28А нче йорт, торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка җиткерү, «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштыру.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бута авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Бута авыл
җирлеге башлыгы Д.Е. Абрамов